| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУСЛЮМОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МӨСЛИМ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.02.2021 М ө с л и м № 59

**«Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 25 гыйнварындагы 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Мәгариф турында» 2020 елның 18 июлендәге 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2021 елның 25 гыйнварындагы 13 номерлы карары белән расланган Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм күрсәтү Тәртибенең 1 пунктында түбәндәге категорияләрне төшереп калдырырга:

1.1. педагогик хезмәткәрләр;

1.2. мәгариф оешмалары җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары;

1.3. мәгариф оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.Т.Демидов**